# Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлегенең Яңа Елань авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карары

13 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Ерсубайкино авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы нигезендә 2025 елның 13 ноябрендә 14 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ерсубайкино авыл җирлеге Яңа Елань авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 4500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, (металл калынлыгына экспертиза, буяу), скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау?» соравы буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 29 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 28 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашучыларның 28 «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде; катнашучыларның 0 «КАРШЫ» позициясе өчен тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлегенең Яна Елань авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - чынбарлыкка туры килә.

2. «Сез 2026 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Ерсубайкино авыл җирлеге Яңа Елань авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 4500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү белән килешәсезме: су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, (металл калынлыгына экспертиза, буяу), скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау?» турындагы мәсьәлә буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Яна Елань авылы, Үзек урамы, 35 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Әлмәт

муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Ерсубайкино авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ерсубайкино авыл җирлеге башлыгы А.В. Быков